

Безгә быел жылы яз килде, ә анын белән бергә Мордовиягә сыерчыклар, vрдәкләр, кыр казлары, челәннәр, каргалар, тургайлар, кызылтvшләр дә кайтты. Язгы кvренеш графиктан алда башланды. Регионыбызнын торле почмакларында кошларны сагынып котеп алабыз. Балалар, әти-әниләре белән бергә, оялар ясап конкурсларда катнаша. Ел саен республикабызнын торле оешмалары жинvчеләрне игълан итә. Мәсәлән, А.С.Пушкин паркы хез-мәткәрләре конкурста катнашкан халыкнын оялар кvргәзмәсен дә оештыра. Аларны зоопаркка кергәндә кvреп була. Шәһәрнен Пролетар районы паркы яннарында урнаштырылган ояларда сыерчыклар оя сайлап гаилә корганнар инде.

Кошларга оя ясаганда орнитологлар кинәшләренә колак салмый булмый. Беренчедән, сыерчык оялары элергә әле сон тvгел. Тик бу эштә минимализм моһим. Тагы оянын тишеге коньякка карап торырга тиеш, бернинди бизәкләр кирәкми. Кошлар аулак урыннар ярата, икән. Оялар агачтан булырга тиеш. Икенчедән, кош баласын этләр яки песиләр таламасын очен, аны кvтәреп агач ботагынын биегенә утыртып кую аларнын гомерләрен саклый.



Апрель башы белән Темников районы Митрялы авылы клубында «Безнен канатлы дуслар» викторинасын Зәйнәп Шамиль кызы Утешева уздырган. Кошлар табигатьнен бер олеше булып тора һәм алар безнен тугры ярдәмчеләребез; урманнарны, кырларны,

бакчаларны саклаучылар, дип Зәйнәп Шамиль кызы укучыларга анлата. Аннары бергәләп кошларны ашатканнар һәм олылар ярләмендә эшләгән сыерчыкларга оялар элеп куйганнар.Тагы Ромоданово районы Алтар топ мәктәбе беренче сыйныф укучысы Амерханова Сәидә «Экология. Балалар. Ижат» республика конкурсында катнаша. Анын эшләнмәләре бик кызыклы һәм гадәти булмаган булып чыккан: моһим темаларга балаларча караш кvренә - табигать турында кайгыртуда кошларга унай шартлар тудыруда чагыла.
Кошлар турында кызык мәгълуматны орнитолог- лар болай ди. Аларнын сvзләренчә, табигать кошларны һава торышын фаразлаунын уникаль механизмы белән бvләкләгән: ул тогәллек буенча кешелек технологияләреннән остен. Кошлар атна-ун кон алга һава торышын белә. Монын ничек шулай булуы фәнгә билгеле тvгел. Тәжрибә мәгълvматлары буенча, кошларнын vз-vзләрен тотышы буенча аларнын кешеләргә караганда һава торышын кvпкә яхшырак тозvен анларга була, икән. Алар климатик шартларга һәм якты кон озынлыгына карап кvчә.
Кошлар безнен дусларыбыз да, ярдәмчеләребез дә. Мәсәлән, сыерчыклар ефәк кvбәләге кортын юкка чыгара, ә чыпчыклар – бакча санитарлары икәне дә безгә билгеле. Чыпчыклар божәкләрне ашаудан тыш, кирәкмәгән чvп vләннәренен – алабута, бәпкә чирәме орлыкларын да бик кvпләп ашый. Өлеге кvренеш тә безгә ярдәме белән кыйммәтле.
Ярдәмебезне кызганмыйча, туган якларына кайткан кошларга ярдәм итәбез, оялар куябыз.

**Н.ХӘЛИЛ**